Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман- Кәләй авыл җирлегенең
Кәләй тимер юл станциясе бистәсе өлешендә
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карар

25 декабрь 2023 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе бистәсе өлешендә гражданнар җыены йомгаклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 декабрендәге хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Урман- Кәләй авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге Кәләй тимер юл станциясе бистәсе өлешендә 2023 елның 24 декабрендә гражданнар җыены узмаган дип танырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н.Фәләхиев